

# «ТАТАР КЫЗЫ»

# ГАББАСОВА АЛЬБИНА РАИЛЬ КЫЗЫ

# МИН СӘНГАТЬКӘ ГАШЫЙК КЕШЕ.



ҖЫРЛАРГА




БИЕРГӘ...

САЙРАТ, САЙРАТ ГАРМУНЫҢНЫ,
ҖИЛКЕНСЕННӘР ЯШЬ КЫЗЛАР;
БЕЗНЕҢ КЫЗЛАР НУРЛЫ ЙӨЗЛЕ,
ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ ЙОЛДЫЗЛАР.





ИХ, ШОМА БАСАБЫЗ,
БИЕП КҮҢЕЛ АЧАБЫЗ!





Шаулат, шаулат бию көен,
Ашкынсыннар барсы да;
Яшь кызларны чакырсыннар,
Кызлар чыксын каршыга



Әйдә, әйдә катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр;
Баскан җирдән ут чыгара
Безнең Альбина, дисеннәр.

Макта, макта: безнең Альбина
Ничек җитез атлый.
Биергә дә оста ул,
Эштә дә сынатмый.



# МИЛЛИ РИЗЫКЛАР ПЕШЕРЕРГӘ





ЯРАТАМ.

Шулпалы бәлеш.

Мичтә пешкәндә үк исе борынны кытыклап, күңелгә үткән, кызарып пешеп җиткәч, табынны түгәрәкләп, гадәти көнне дә бәйрәмчә хисләргә төрүче ризыгыбыз – бәлеш бар. Татарда бәлешнең төрлесе бар, баллысы, балсызы, җимешлесе, ярмалысы... Шулай да өстәл түрен инде күптән бәрәңгеле-итле бәлеш биләп тора. Хәзер мин сезне тәмле ит бәлеше пешерергә өйрәтәм.

**Шулпалы бәлешне төче камырдан ясыйлар. Аны, гадәттә, кайнаган салкын суга тоз, мул итеп көнбагыш мае, чеметем генә чәй содасы салып, бик үк каты булмаган камыр басыла. Эчлек өчен бәрәңгене шакмаклап ваклап турыйлар, аңа шулай ук вак туралган тәмле йомшак ит белән суган салалар һәм тәменчә тоз, борыч өстәп бутыйлар. Майланган табага җәел-гән камырны куеп, эчлекне шунда бушаталар, тигезлиләр дә, өстен тагын җәелгән камыр белән каплап, ян-якларын бөрәләр. Бәлеш әзерләүнең сере – пешерүдә! Бәлеш гадәти газ мичендә 2 сәгать дәвамында пешәргә тиеш. Мич никадәр генә "ышанычлы" исәпләнсә дә, бәлешнең камыры катып китмәсен өчен аска сулы савыт куялар. Бәлеш исе чыга башлагач, газны кысып куялар һәм шулай талгын утта астын да, өстен дө көйдермичә, ара-тирә мич ишеген ачып карап пешкәнен күтәләр. 2 сәгать тула башлаганда, бәлеш өстенә әкрен генә кайнар су бөркиләр – ул шулай камыр өстен йомшартып җибәрә. Бәлеш уртасында кечкенә капкач ясап калдырып, шунда вакыт-вакыт шулпа салып пешерү гадәте дә электән бар. Ризыкларыгыз тәмле булсын!**

# МИН ПЕШЕРГӘН БӘЛЕШЛӘР, ПӘРӘМӘЧЛӘР,КҮМӘЧЛӘР...





Күңел белән сөям
Бәхетен татарның,
Татар бит мин,
Үзем дә чын
Татар кызымын.

Альбина Габбасова